ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Рече
Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№1** **18 октябрь 2022 ел**

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 29 октябрендә 13.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенә керүче Хөррият торак пунктында Татарстан Республикасы Ютазы районы, Хөррият авылы, Хөррият урамы, 5 нче йорты каршында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенә керүче Хөррият торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме:

- Хөррият торак пунктында зират коймасын урнаштыру (материаллар сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, транспорт чыгымнары).
- Хөррият торак пунктында зиратта хуҗалык инвентаре өчен бина төзү (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, транспорт чыгымнары).

«ӘЙЕ» «ЮК».

2. Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән (халыкка җиткерелгән) үз көченә керә.

"Ташкичү авыл җирлеге"
муниципаль берәмлек башлыгы Р.К.Вәлиев